ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

______________　　с. Верхний Услон　　______________

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгының җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең уңайлы шартларга хокукларын, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмә нигезендә, Хәйруллин М.Ф. мөрәҗәгатен карап

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Яр буе Морквашы авыл җирлеге, Яр буе Морквашы авылы, Красавин ур., 32 йорт адресы буенча урнашкан 16:15:120101:347 кадастр номерлы, 1 749 кв. м мәйданлы – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Яр буе Морквашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре индивидуаль торак йортлар (Ж1) төзү зонасында «Кибетләр» булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Министрлык боерыгы проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карап тикшерү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы).

2.2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча 2025 елның 16 июленнән алып 2025 елның 4 августына кадәр, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмә нигезендә иҗтимагый фикер алышулар үткәрү.

2.3. Экспозиция проектын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яшьләр-яшүсмерләр клубы бинасы, 2025 елның 16 июленнән алып 2025 елның 4 августына кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты. Тәкъдимнәр, искәрмәләр 2025 елның 16 июленнән алып 2025 елның 4 августына кадәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбеләрдә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә һәм (яисә) Alina.Sagdeeva@tatar.ru электрон почтасы аша кабул ителә.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга проект буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетына әлеге рөхсәтләр соратылган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә җиткерү өчен хәбәр җибәрергә.

4. Мөрәҗәгать итүче гр. Хәйруллин М.Ф. иҗтимагый фикер алышуларны оештыруны техник яктан тәэмин итәргә, шул исәптән экспозиция үткәргәндә һәм әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын хокук ияләренә җиткергәндә.

5. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

5.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

5.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яшьләр-яшүсмерләр клубы бинасында һәм «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» вкладкасында Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмати стендта проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр урнаштырырга.

5.3. 2025 елның 16 июленнән дә соңга калмыйча Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, "Архитектура һәм шәһәр төзелеше" вкладкасында урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Яр буе Морквашы авыл җирлеге, Яр буе Морквашы авылы, Красавин ур., 32 йорт адресы буенча урнашкан 16:15:120101:347 кадастр номерлы, 1 749 кв. м мәйданлы – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Яр буе Морквашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре индивидуаль торак йортлар (Ж1) төзү зонасында «Кибетләр» булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Министрлык боерыгы проекты.

5.4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яшьләр-яшүсмерләр клубы бинасында, әлеге карарның 5.3 пунктында күрсәтелгән проектлар буенча, 2025 елның 16 июленнән алып 2025 елның 4 августына кадәр, эш көннәрендә 8.00-12.00 сәгатьләрдә, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында экспозицияләр оештырырга.

5.5. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин